РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ГЛАВА ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

Ленина ул., д. 46, с. Тюлячи, 422080

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

Ленин ур., 46 нчы йорт, Теләче авылы, 422080

тел. (факс): (843) 602-11-89, E-mail: telache@tatar.ru, http://tulachi.tatarstan.ru/

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 58** **«20» декабря 2019г.**

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башлыгының «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында гражданнар оборонасы чараларын тәэмин итү һәм коткару хезмәтләрен (гражданнар оборонасы хезмәтләрен) төзү турында» 2016 елның 21 мартындагы 26 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 30.09.2009 елның 30 сентябрендәге 1274 номерлы карары нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында гражданнар оборонасы чараларын тәэмин итү һәм коткару хезмәтләрен (гражданнар оборонасы хезмәтләрен) булдыру турында» Теләче муниципаль район Башлыгы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) Гражданнар оборонасы чараларын тәэмин итү турында нигезләмә:

А) 9 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: "гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрне кисәтүнең һәм бетерүнең бердәм дәүләт системасын булдыру, җиһазландыру һәм әзерләү, шулай ук аларның гамәлләрен планлаштыру;";

Б) 12 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: "Россия Федерациясе территориясендә радиацион, химик, биологик хәлне күзәтү һәм тикшереп тору функцияләрен гамәлгә ашыручы, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары һәм оешмалары - федераль башкарма хакимият органнары, бүлекчәләре һәм хезмәтләре булган махсус учреждениеләр, Россия Федерациясе субъектларының һәм Теләче районы территориясендә урнашкан оешмалар-гражданнар оборонасын күзәтү һәм лаборатор контрольдә тоту челтәрен булдыру һәм әзерлекне тәэмин итү";

В) 18 пунктның дүртенче абзацында "планнарны эшләү һәм төзәтү" сүзләрен "планлаштыру"сүзенә алмаштырырга.

2) күрсәтелгән карар белән расланган Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы гражданнар оборонасы хезмәтләре җитәкчеләре исемлеген (4 нче кушымта) түбәндәге тәртиптә бәян итәргә:

| № | Хезмәт атамасы | Бүлек җитәкчесе |
|---|---|---|
| 1 | Элемтә һәм хәбәр итү хезмәте | Арча ЗЭЭТ ы район электр челтәрләренең Теләче цехы җитәкчесе Гарифуллин И. И. |
| 2 | Медицина хезмәте | "Теләче РҮХ" ДАССУ ның баш табибы Галиуллин Ирек Илгиз улы |
| 3 | Җәмәгать тәртибен саклау хезмәте | Россия Эчке эшләр министрлыгының Теләче муниципаль районындагы бүлек начальнигы Зарипов Илшат Сәгыйт улы |
| 4 | Янгынга каршы хезмәт | № 134 янгын бүлеге башлыгы Шәрипов М. М. |
| 5 | Транспорт хезмәте | Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге транспорт бүлеге начальнигы Мараков Илдар Рамлевич |
| 6 | Юл хезмәте | "Татавтодор" ачык акционерлык җәмгыятенең Арча филиалының Теләче ЮТТИ җитәкчесе Ярмиев Илнур Зиннур улы |
| 7 | Энергетика һәм яктылыкны маскировкалау хезмәте | Алабуга электр челтәрләренең Теләче участогы начальнигы Якупов Рөстәм Шөгаеп улы |
| 8 | Инженерлык хезмәте | Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге начальнигы Валеев Фаат Самик улы |
| 9 | Коммуналь-техник хезмәт | "Мишә" ҖЧҖ җитәкчесе Зиннәтуллин Илсур Кәримулла улы |
| 10 | Сәүдә һәм туклану хезмәте | Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең территориаль үсеш һәм инвестицияләр буенча урынбасары Миңнегулов Илдар Әмин улы |
| 11 | Хайваннарны һәм үсемлекләрне яклау хезмәте | Теләче муниципаль районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе начальнигы Низаметдинов Ралиф Хәниф улы |

2. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Теләче муниципаль район
Башлыгы урынбасары А. Г. Фәтхуллин